**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур, 9а

**СОВЕТ СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с.Суксу, ул. Школьная ур, 9а

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

---

**КАРАР**
**26 май 2020 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 186**

## Суыксу авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 28 нче ноябрендә кабул ителгән 173 нче номерлы “Җир налогы турында” карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге " муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Суыксу авыл җирлеге Советының 2019 нчы елның 28 нче ноябрендә кабул иткән 173 нче номерлы “Җир налогы турында” карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә»:

1) 5 пунктта. “салым түләүче-оешмалар” сүзләрен төшереп калдырырга»;

2) 5.1, 5.2 пунктларны “ төшереп калдырырга”;

3) 7.1 пунктының 4 абзацындагы икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ташламаны бирү өчен нигез булып Бөек Ватан сугышы ветераны таныклыгы яисә сугышта катнашучы таныклыгы, күрсәтелгән ташламаны алу хокукын раслаучы башка тиешле документлар тора»

4) 3 пунктны 3.1.1 киләсе эчтәлектәге пункт белән тулыландырырга:

«3.1.1. Салым түләү салым түләүчеләр тарафыннан җир кишәрлекләре урнашкан урын буенча башкарыла.

Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал тәмамланганнан соң, узган хисап чорыннан соң киләсе айның 5 числосыннан да соңга калмыйча җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы ¼ күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.»

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтына http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталына http://pravo.tatarstan.ru/. урнаштырып халыкка җиткерергә.

3. 3.1.1 пунктының икенче абзацы 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көчен югалта.

4. Әлеге карар Россия Федерациясе Салым кодексының 5 статьясы нигезендә үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлеше контролен үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге Башлыгы урынбасары Р.Р.Гатауллин